Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Корноухово авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 5**

Корноухово авылы 2022 елның 24 июне

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Корноухово авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге милкендәге өченче затлар хокукларыннан (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан гайре) азат булган, муниципаль мөлкәт исемлегенә кертелгән һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга бирү өчен аталган, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Корноухово авыл җирлеге Советының 2018 елның 12 октябрендәге 13 номерлы карары белән расланган муниципаль мөлкәтне арендага бирү Тәртибенә һәм шартларына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында, “Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында” 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 23 декабрендәге “Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга бирү өчен билгеләнгән, Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәт исемлегенә кертелгән, өченче затлар хокукларыннан (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан гайре) азат булган дәүләт мөлкәтен арендага бирү тәртибен һәм шартларын раслау турында” 976 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 25 мартындагы “Татарстан Республикасы милкендәге өченче затлар хокукларыннан (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан гайре) азат булган, Татарстан Республикасы мөлкәте исемлегенә кертелгән һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче

оешмаларга бирү өчен аталган, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 23 декабрендәге 976 номерлы карары белән расланган дәүләт мөлкәтен арендага бирү Тәртибенә һәм шартларына үзгәрешләр кертү турында" 170 номерлы карары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Корноухово авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Корноухово авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Корноухово авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге милкендәге өченче затлар хокукларыннан (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан гайре) азат булган, муниципаль мөлкәт исемлегенә кертелгән һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга бирү өчен аталган, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Корноухово авыл җирлеге Советының 2018 елның 12 октябрендәге 13 номерлы карары белән расланган муниципаль мөлкәтне арендага бирү Тәртибенә һәм шартларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3.2. Аренда түләве күләме коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә, техник хезмәт күрсәтүгә, арендага бирелгән мөлкәтне саклауга чыгымнарны һәм күрсәтелә торган мөлкәтне карап тотуга һәм эксплуатацияләүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган башка чыгымнарны, шулай ук мөлкәтне мәҗбүри иминиятләштерүгә чыгымнарны, җир кишәрлегеннән файдаланган өчен түләүне үз эченә алмый.";

1.2. 3.3 пунктының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3.3. Мөлкәтне арендалаган өчен түләүгә ташлама индивидуаль эшкуарлар булмаган һәм "Һөнәри керемгә салым" махсус салым режимын кулланучы физик затларга, мөлкәт арендалаучы һәм авыл хуҗалыгы кооперативлары булган яисә эшчәнлекнең социаль әһәмиятле төрләре белән шөгыльләнүче, Россия Федерациясе дәүләт программаларында (ярдәмче программаларында), Татарстан Республикасы дәүләт программаларында (ярдәмче программаларында), эшчәнлекнең өстенлекле төрләре буенча муниципаль программаларда (ярдәмче программаларда) билгеләнгән башка программаларда катнашучы кече һәм урта эшкуарлык субъектларына бирелә. Күрсәтелгән ташлама түбәндәге зурлыктагы аренда түләвен билгеләүдән гыйбарәт:";

1.3. 3.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3.4. Әлеге Тәртипнең 3.3 пунктында каралган шартларда төзелгән мөлкәтне арендалау шартнамәсе мөлкәтне арендалау шартнамәсе буенча йөкләмәләрне арендатор үтәмәүгә бәйле рәвештә яки арендатор әлеге тәртипнең 3.3 пунктында каралган критерийларга туры килми башлаган очракта вакытыннан алда өзелгәндә дәүләт мөлкәтеннән фактта файдалануның бөтен вакыты, аны төзү хокукына сату нәтиҗәләре буенча мөлкәтне арендалау шартнамәсендә билгеләнгән аренда бәясеннән 100 процент күләмендә түләнергә тиеш.".

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Корноухово авыл җирлегенең Корноухово авылы, Совхоз урамы, 3 йорт; Зюзино авылы, Үзәк урамы, 6 йорт,Чирмешан, Советлар урамы, 21 йорт; Наумово

авылы,Наумово урамы, 3 йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Корноухово авыл җирлеге Башлыгы Г.С Гумашян